5.8.1. – Общая педагогика, история педагогики и образования
**Ссылка для цитирования:**
Мөбәрәкшина А.Р. Татар теле дәресләрендә милли ММЧ медиаресурслары: интерактив күнегүләр төзү һәм куллану алымнары // Современное образование: актуальные вопросы и инновации. 2024. № 2 (21). URL: http://irortsmi.ru/wp-content/uploads/2024/07/2024_2_mubarakshina.pdf

УДК 372.881

**Алия Раифовна Мөбәрәкшина**
Казан шәһәре Идел буе районы «186 нчы номерлы күппрофильле лицей – «Перспектива» муниципаль бюджет белем бирү учреждениясенең татар теле укытучысы

# Татар теле дәресләрендә милли ММЧ медиаресурслары: интерактив күнегүләр төзү һәм куллану алымнары[1]

***Аннотация.*** Заманабыз балалары гаджетлар, ИК-технологияләр чорында үсәләр. Татарстан Республикасы җитәкчелеге тарафыннан балалар өчен күп кенә татар телле медиапроектлар тормышка ашырылып килә.Бу үз чиратында әлеге медиаресурсларны белем бирү процессына кертүне көн тәртибенә куя. Укучылар «Шаян ТВ» и «Татмедиа-Junior» кебек балалар каналларының медиаресурслары кызыксындырырга мөмкин. Әлеге каналлар татар мәдәниятен, көнкүрешен, классик һәм бүгенге чор әдәбиятын, табигатен, туган якның хайваннар дөньясын һәм башкаларны анлаешлы итеп яктырталар. Дәресләрдә медиаресурсларны интерактив күнегүләр формасында башлангыч сыйныфлардан ук куллану укучыларны туган телләрендә дәресләрдә генә түгел, көндәлек тормышта да сөйләшү теләге барлыкка китерә.

***Ачкыч сүзләр.*** «Татмедиа-Junior», «Шаян ТВ», «СалаваTIK», интерактив ысул, интерактив ысул алымнары,»кар йомарламы», ми штурмы, «вордклауд–сүзләр болыты», кроссворд, ребус, пазл, интервью, мини-спектакль

**Aliya R. Mubarakshina**
Teacher of Tatar language, Multidisciplinary lyceum 186 – “Perspective” of the Volga district of Kazan, Russia

# Methods of Using National Media in Tatar Language Lessons: Creating Interactive Tasks

***Abstract.*** Modern children grow up in the era of gadgets and ICT technologies. With the support of the leadership of the Republic of Tatarstan, many media projects for children in the Tatar language are being implemented. In turn, these media resources must be included in the learning process. Children may be interested in the media resources of the children’s TV channel "Shayan TV" and "Tatmedia-Junior", which in the most accessible form illuminate Tatar culture, everyday life, classical and modern literature, as well as nature, the animal world of their native land, etc. The use of these media resources in the classroom plays an important role in motivating a child from primary school to use his native language not only in the classroom, but also in everyday life.

***Keywords:*** "Tatmedia-Junior", "Shayan TV", interactive methodology, techniques of interactive methodology, "snowball", brain-storming, word cloud, crossword, rebus, puzzle, interview, mini-performance

Заманча татар телен укыту методикасы гасырдан артык тарихы булган традицион укыту ысулларының интерактив алымнар белән үрелеп үсешенә йөз тотты. Бердәнбер татарча балалар телеканалы «Шаян ТВ» һәм «Татмедиа-Junior» интернет платформалары укучы-

[1] Мәкалә ТР Фән һәм мәгариф министрлыгының «Безнең яңа укытучы» гранты кысаларында әзерләнде

© Мубаракшина А.Р., 2024

ны татарча тыңларга, аңларга, фикерләүгә һәм сөйләшүгә китерә торган кызыклы медиаресурслар тәкъдим итә. Онлайн-дәресләр, социаль экспериментлар, интеллектуаль бәйгеләр, Татарстан буйлап сәяхәт, фольклор, классик һәм заманча җырлар, җырлы уеннар һ.б. юнәлешләрне яктырткан медиа-проектлар арасында башлангыч сыйныфта татар теле дәресләрендә кулланырга мөмкин булган күп кенә кулланма материаллар бар. «Шаян ТВ» телеканалының «Шаян әлифба», «Шаян саннар», «Алты хәреф», «Аңла», «Шаян дәрес», «Кичке әкиятләр» проектлары [1], «Салават күпере» һәм «Сабантуй» журналлары редакциясендә тормышка ашырыла торган «СалаваТIК», «Бәби сүз», «Беләсем килә», «Шәвәлидән сора», «Тәҗрибә», «Идел» журналы редакциясенең «Социаль эксперимент», «Сораштыру» видео-материалларын төрле инновацион технологияләр аша рус телле укучыларга татар телен укытуда башлангыч сыйныфларда уңышлы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин. Татар милли журналистикасының максаты татар яшьләре өчен карарга кызыклы һәм мәгълүматка бай тапшырулар эшләү булса, татар теле укытучысының шул тапшырулар нигезендә балада ана теле предметына карата кызыксындыру уяту һәм татар сөйләмен көндәлектә куллануга этәрү. Дәрес барышын кызыклы итәр өчен ММЧ видеоматериалларын мәгълүмати технологияләргә караган пазл җыю, кроссворд, сканворд, викторина, лексик карточкалар, кроссенс (сюжетлы рәсемнәр), сүзләр болыты (Word Art Cloud) кебек эш төрләре белән баетып бирергә мөмкин. Моның өчен укытучыга, Quiziz, Quizlet, Etreniki, WardWall, Joyteka интернет платформаларында теркәлеп, укучыларының белем дәрәҗәсен күздә тотып, интерактив күнегүләр эшләү зарур.

«Салават күпере» журналы редакциясе тормышка ашыра торган «Бәби сүз» тапшыруында төсләр, формалар, саннар, уенчыклар, савыт-саба, кыргый/ йорт хайваннары, кошлары, агачлар турындагы белемнәрне алып баручы кечкенә кыз Зөбәйдә тест формасында тикшерә. Тапшыруны караучы бала дөрес җавапны сайлап алырга һәм кабатларга тиеш [2]. Тапшыру табышмак, викторина, сорау-җавап рәвешендә төшерелгән һәм аны дәрестә билгеле бер лексиканы кабатлаганда кулланырга мөмкин. Зөбәйдә сорауларны биргәндә, укучы аның сорауларына җавап эзли. Бала тапшыруны алып баручы белән, үзе дә сизмәстән, татарча әңгәмә кора. Режиссер бик кызыклы алым файдалана: экран каршында утыручыга җавапны уйлап табар өчен бернечә секунд буш вакыт бирелә, шуннан соң гына Зөбәйдә «Әйе, дөрес» дип, җавапны әйтә, үзе белән берлектә җавапны кабатларга чакыра, экранга җавап – кирәкле сүз иҗекләргә бүленгән рәвештә һәм сүз басымы куелып чыга. Дәрестә бу төр видеоматериаллар нигезендә, интерактив алымнардан «кар йомгагы», «карусель» алымнарын куллану отышлы. Ул пассив лексиканы активка күчерергә, укучыга үзара диалог корырга ярдәм итә.

**«Беләсем килә»** проектында төрле темага кагылышлы һәр бала белергә тиешле мәгълүматны диктор талгын һәм анык сөйләм аша җиткерә [3]. Җөмләләр гади һәм җиңел аңлаешлы, аудирование өчен җайлы материал. Рус телле балага әлеге ресурсларны тәкъдим итәр өчен алдан ук сүзлек белән эшләү мөһим. Тән әгъзалары, яшелчәләр, ризыклар, ярмалар,ел фасыллары,агачлар, чәчәкләр,бөҗәкләр, кошлар, кыргый җәнлекләр, диңгез хайваннары һ. б. темаларны яктырткан 2–3 минутлык видеолар кечкенә балалар өчен кызыклы сюжетлы рәсемнәр белән баетылып бирелә. «Беләсем килә» тапшыруындагы иң төп фикерне отып калу, төп лексиканы истә калдыру, кабатлау, ныгыту максатыннан «футбол тубы» алымы, кроссворд алымнарын куллану отышлы. «Шакмак» алымы төп мәгълүматны аңлау, анализлау, диалогка керү, монолог сөйләүгә дә этәрергә мөмкин.

**«СалаваТik»** җырлары — текстны акустик яктан кабул итү һәм укып аңлауга китерә [4]. «СалаваТik» җырларын сөйләм һәм язма күнекмәләрне ныгыту өчен, аерым алганда, телнең фонетик, лексик, грамматик кагыйдәләрен искә төшерү, кабатлау, тирәнәйтүдә төрле биремнәрдә кулланырга мөмкин. Салаватик җырларын фонетик күнегүләр эшлә-

гәндә еш кына карточкалар белән парлар, йә төркемнәрдә эшләү уңайлы. Лексик күнегүләрдә метафора, чагыштырулар белән эшләү баланың тел байлыгын гына түгел, фикерләү сәләтен дә арттыра.

**«Шаян әлифба»** җырларында яңгыраган сүзләрне истә калдыру һәм дөрес язу өчен интерактив күнегүләрдән кроссворд алымы уңай нәтиҗәсен бирә [1]. Кроссворд — укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыручы мавыктыргыч дидактик уен. Кроссворд билгеле бер лексиканы истә калдыру, кабатлау һәм җанлы сөйләмдә шул сүзләрне куллануга этәрә. «Шаян әлифба» татар теле алфатиның һәр 39 хәрефенә багышланган җырлар тупланмасыннан гыйбарәт. Кроссворд шакмакларына яшергән дүрт сүзне фонетик күнегү эшләгәндә бала логик фикрләү һәм хәтерендә калдыру ярдәмендә тиз генә чишә. Биремне катлауландыру өчен, укучы еш бутый торган авазларны бер кроссвордта бирергә мөмкин. Мисалга, рус телле бала [ә], [э] авазларын бутый. Моннан котылу өчен, «әби», «әти», «әни», «әтәч» сүзләре янәшәсендә «эт», «эз», «энә», «энҗе» сүзләрен китерү уңышлы. Кроссвордны чишкән вакытта бала ике хәреф һәм аваз арасындагы аерманы тоемларга өйрәнә.

«Шаян ТВ» каналының **«Аңла»** дип аталган тапшыруын рус телле балалар аеруча яратып карый [1]. Ул — уен форматында эшләнгән 3 минутлык видео. Колакчан таккан бала иптәшенең нәрсә әйткәнен аңларга тиеш. Бу рус телле балага артикуляцион күнекмәләрне ныгытырга, сөйләм органнарының авазларны әйткәндәге эшчәнлеген күзәтүгә игътибарлылыкны арттыра. «Аңла» уенын теге яисә бу авазны кабатлаганда, фонетик күнегү буларак та, лексик күнегү буларак та җиңел генә дәрес барышына кертеп җибәрергә мөмкин. Моның өчен музыка, колакчан һәм карточкалар кирәк.

**«Алты хәреф»** проекты татар фольклорын яшь буынга җиткерүдә, аерым алганда, халык мәкальләрен өйрәнүдә зур өлеш кертә [1]. Татар теленең милли үзенчәлекләрен, милли кодны аңламаган рус телле бала өчен татар мәкальләрен истә калдыруы бик кыен. Синтаксик фигура буларак, мәкаль — сөйләмне җанлы һәм тасвирлы итә, ул фәлсәфи фикерләү куәсенә ия, тормыш белән өзлексез мөнәсәбәттә булган тел берәмлеге. Тел байлыгын арттыру максатында, «Алты хәреф» материалларын дәрестә ребуслар ярдәмендә үзләштерү уңайлы. Бер төркем укучылар актив лексика ярдәмендә мәкаль яшерелгән ребус төзесә, икенче төркем шул ребусны чишәргә омтыла. Ребусны һәм төзегән, һәм чишкән вакытта логик фикерләү үсә, лексик берәмлекләр хәтердә тизрәк кала.

**«Кичке әкиятләр»** тапшыруын тыңлау аша рус телле укучыда дөрес сөйләү һәм сәнгатьле уку күнекмәсе булдырыла [1]. Укучы алып баручының эмоциональ интонациясен отып кала һәм аны кабатларга тырыша. Бу төрдәге имитатив метод сөйләм осталыгын, күнекмәләрен формалаштырганда мөһим фактор булып тора. Бу төр тапшыруларны тыңлагач, «Сүзләр болыты» технологиясе аша монологик сөйләмгә чыгарга җайлы. Истә калган сүзләрдән сыйныф бергәлектә куе сүзләр болытын ясый. Иң әһәмиятле сүзләрне болытка урнаштырып, бербөтен текст төзергә тырыша.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: мәктәп укучылары өчен милли матбугат чаралары тәкъдим иткән онлайн медиаресурслар татар халкының мәдәнияте, сәнгате, бай мирасына, татарларның көнкүрешенә, туган як табигатенә карата кызыксынуны арттыра, татар теленең милли картинасын күзаллауны булдыра. Шәһәр шартларында татар телен өйрәнүче балаларга мәгълүматны җиңел үзләштерергә мөмкинлек тудыра.

Әдәбият

1. Шаян: сайт. Казань. URL: https://shayantv.ru (дата обращения: 10.03.2024).
2. Бәби сүз: «Салават күпере». URL: https://www.youtube.com/results?search_query=бәби+сүз (дата обращения: 10.03.2024).

3. Беләсем килә: «Салават күпере». URL: https://www.youtube.com/results?search_query=беләсем+килә (дата обращения: 10.03.2024).
4. СалаваTIK: «Салават күпере». URL: https://www.youtube.com/results?search_query=салаватик (дата обращения: 10.03.2024).
5. «Сабантуй» балалар журналы: сайт. Казань. URL: https://sabantuyjournal.ru (дата обращения: 10.03.2024).

References

1. Shayan. URL: https://shayantv.ru (accessed: 10.03.2024).
2. Bəbi syz. “Salavat kyperE”. URL: https://www.youtube.com/results?search_query=бәби+сүз (accessed: 10.03.2024).
3. Beləsem kilə. “Salavat kyperE”. URL: https://www.youtube.com/results?search_query=беләсем+килә (accessed: 10.03.2024).
4. SalavaTIK. “Salavat kyperE”. URL: https://www.youtube.com/results?search_query=салаватик (accessed: 10.03.2024).
5. “SabantuI”. URL: https://sabantuyjournal.ru (accessed: 10.03.2024).